**Садыйкова Т. Тукайның туган көне: (Әдәби-музыкаль кичә) // Мәгариф.- 1995.- № 3.- Б.8.**

# Тукайның туган көне

(Әдәби-музыкаль кичә)

*Зал зәвык белән бизәлгән. Каршыга Г. Тукай портреты, аның турында бөек кешеләрнең сүзләре язылган плакатлар эленгән. Олы әдип әкиятләренә ясалган рәсемнәрдән күргәзмә оештырылган. Балалар шагыйрь сүзләренә язылган **«Бәйрәм бүген»** дигән җырны башкара.*

**Алып баручы.** Укучылар, бүген чыннан да зур бәйрәм! Г. Тукайның туган көне! Безнең мәктәптә бу бәйрәмгә әзерлек күптән бара. Шагыйребезнең әсәрләрен иң күп белүче, аңа багышланган викторинада җиңеп чыгучы балалар бүгенге кичәдә катнашу бәхетенә иреште. Әйдәгез, аларны каршылыйк! *(Җиңүчеләрнең исемнәре әйтелә. Алар алга чыгып баса. **«Тукай абый»** дигән җыр башкарыла.) (З. Туфайлова шигыре, М. Шәмсетдинова музыкасы).*

**Уенның I туры башлана**. Алып баручы балаларга сорау бирә. Балалар, сез беләсез инде, кечкенә Апушка бик күп гаиләләрдә булырга, авылдан авылга күчеп йөрергә туры килгән. Тыңлагыз әле, бу юлларны ул кайсы авылда яшәгән елларын искә төшереп язган? «Үги әбинең алты күгәрчене эчендә мин бер чәүкә булганга, мине еласам — юатучы, иркәләним дисәм — сөюче булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр».

**Җавап. Өчиле** авылы турында.

*Спонсор — ата-аналар комитеты балаларга бүләк тапшыра.*

*«**Бала белән күбәләк**» исемле җырлы бию башкарыла. (Г. Тукай шигыре, Ф. Әбүбәкеров музыкасы.)*

**II тур.**

**Сорау.** Г. Тукай сүзләренә бик күп җырлар язылган. Шуларның берсен уйнап күрсәтегез әле.

*Курайчылар «**Тәфтиләү**» көен башкара.*

**Алып баручы**. Нинди көй булды бу, укучылар?

**Җавап**. «**Тәфтиләү**». *(Дөрес җавап бирүчеләр бүләк ала.)*

**III тур.**

**Сорау**. Г. Тукай Уральск шәһәрендә чын мәгънәсендә белем алуга ирешә. Ул укыган мәдрәсәнең исеме нинди?

**Җавап**. Мотыйгыя.

*Малайлар «Мәдрәсәдә булган хәл» дигән ша*
*(Бүләкләр тапшырыла.)*

**IV тур.** Тамашачылар белән уен.

**Алып баручы**. Мин бер шигырь укыйм. Ул юллар Г. Тукайның кайсы шигыреннән алынган?

Җен-фәлән дип сөйләнүләр
Искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле —
Шагыйранә ялган ул.

**Җавап**. «Сабыйга» шигыреннән.

**Сорау**. Бу җырны ул яңадан Казанга өйләнеп кайтканда яза. Ул нинди җыр? Тукай Казанда кайсы кунакханәдә яшәгән?

**Җавап.** Талгын гына «**Пар ат**» җыры яңгырый. «Болгар».

**V тур**. Хәлиткеч уен.

**Сорау.** «Шүрәле» дигән беренче татар балетының авторы кем?

**Җавап.** Фәрит Яруллин.

*Дөрес җавап бирүчеләргә бүләк тапшырыла. Г. Тукайның «Шүрәле» әкиятеннән өзек күрсәтелә. Бер төркем укучылар «Шүрәлеләр биюе»н башкара.*

*Кичә аягүрә басып, Г. Тукай сүзләренә язылган «**Туган тел**» җырын җырлап тәмамлана!*

Тәслимә САДЫЙКОВА,

Казандагы 42 нче мәктәп-гимназия